БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
10 ноябрь 2025 ел

**КАРАР**
№ 17

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне арендага бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Балтач районы прокуратурасының 2025 елның 25 сентябрендәге 02-08-01-2025/Прдп377-25-20920011 номерлы протестын карап, «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. Балтач район Советының 2019 елның 25 июлендәге 201 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне арендага бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Әгәр балалар өчен социаль инфраструктураны барлыкка китерә торган муниципаль оешма арендага бирсә, аренда шартнамәсен төзер алдыннан гамәлгә куючы тарафыннан «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 2 пунктында билгеләнгән тәртиптә мондый шартнамәне төзүнең балаларның тормыш эшчәнлеген, белем алуын, үсешен, ял итүен һәм сәламәтләндерүне, аларга медицина ярдәме күрсәтүне, балаларда авыруларны профилактикалауны, аларны социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итү нәтиҗәләрен бәяләү үткәрелергә тиеш.

Әгәр аларны төзүне бәяләү нәтиҗәсендә әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән шартларның начараю ихтималы билгеләнсә, аренда шартнамәсе төзелә алмый.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары,
Балтач район Советы рәисе урынбасары Н.Н. Сабирҗанов